РУКОВОДИТЕЛЬ
ИСПОЛНИТЕЛЬНОГО
КОМИТЕТА
ВЕРХНЕУСЛОНСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
ВЕРХНЕУСЛОНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
Ул. Чехова, д.54, с. Верхний Услон,
422570

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЮГАРЫ ОСЛАН
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫҢ
ЮГАРЫ ОСЛАН
АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
БАШКАРМА
КОМИТЕТЫ
ҖИТӘКЧЕСЕ
Чехов ур., 54 нче йорт, Югары Ослан авылы,
422570

Тел.: (84379) 30-1-48, факс: (84379) 30-1-48.

ПОСТАНОВЛЕНИЕ                    КАРАР

26.01.2022          с. Верхний Услон          № 4

**Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының Югары Ослан авыл җирлегендә 2022нче елга җирләү буенча хезмәтләр күрсәтүнең гарантияләнгән исемлеге нигезендә күрсәтелә торган хезмәтләр хакын раслау турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Җирләү һәм җирләү эше турында» 12.01.1996 ел, №8-ФЗ Федераль закон, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Җирләү һәм җирләү турында» Федераль законны гамәлгә ашыру чаралары хакында» 2007 елның 18 маендагы 196 номерлы карары нигезендә,

КАРАР БИРӘМ:

1. Югары Ослан муниципаль районы Югары Ослан авыл җирлегендә җирләү буенча хезмәтләрнең гарантияле исемлеге нигезендә 6964,68 сум күләмендә күрсәтелә торган хезмәтләрнең бәясен 2022 елның 1 февраленнән 1 кушымта һәм 2 кушымта нигезендә билгеләргә гамәлгә кертергә.
2. Әлеге карарны Югары Ослан муниципаль районының рәсми сайтында, Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында, шулай ук Югары Ослан авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында урнаштырырга.
3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

Югары Ослан авыл җирлеге
Башкарма комитеты җитәкчесе                    Д. В. Котков

Югары Ослан  авыл җирлеге
Башкарма комитетының
2022нче елның  26нчы
гыйнварыннан  4нче номерлы
карарына

1 нче кушымта

Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы   Югары Ослан  авыл җирлегендә 2022нче елның 1нче февраленнән җирләү буенча хезмәтләрнең гарантияле исемлеге бәясе

| Хезмәт күрсәтү исеме | Хезмәт күрсәтү бәясе (сум) |
|---|---|
| 1. Җирләү өчен кирәкле документларны рәсмиләштерү | - |
| 2.  Табут һәм җирләү өчен кирәкле башка предметларны бирү һәм китерү | 3601,24 |
| 3. Мәрхүмнең җәсәден (гәүдә калдыкларын) зиратка озату | 1116,65 |
| 4. Җирләү (кабер казу һәм күмү) | 2246,79 |
| Барлыгы | 6964,68 |

Югары Ослан  авыл җирлеге
Башкарма комитетының
2022нче елның  26нчы
гыйнварыннан  4нче номерлы
карарына
2нче кушымта

Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы   Югары Ослан  авыл җирлегендә 2022нче елның 1нче февраленнән җирләү буенча хезмәтләрнең гарантияле исемлеге бәясе

| Хезмәт күрсәтү исеме | Хезмәт күрсәтү бәясе (сум) |
|---|---|
| 1. Җирләү өчен кирәкле документларны рәсмиләштерү | - |
| 2. Мәетне кәфенләү | 666,35 |
| 3. Җирләү өчен  табут һәм башка кирәкле предметларны бирү һәм китерү | 2934,90 |
| 4. Мәрхүмнең җәсәден (гәүдә калдыкларын) зиратка илтү | 1116,65 |
| 5. Җирләү (кабер казу һәм күмү) | 2246,78 |
| Барлыгы | 6964,68 |